КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 март г.Казань № 225

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәткә инвентаризация ясау һәм аны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәткә инвентаризация ясау һәм аны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү максатларында «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәткә инвентаризация ясау һәм аны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Тәртипкә таянып эш итүне, муниципаль мөлкәтне инвентаризацияләү нәтиҗәләрен гомумиләштерүне, муниципаль берәмлекләр милкендәге файдаланылмый торган күчемсез мөлкәт объектлары исемлеген, файдаланылмау сәбәпләрен күрсәтеп, раслауны, төркемнәргә бүлүне һәм ел саен, хисап елының 10 декабренә кадәр, инвентаризация нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карарның 2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны гомумиләштерергә һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге файдаланылмый торган күчемсез мөлкәт объектлары исемлеген алып баруны гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 30 көн эчендә бу карарны тормышка ашыру өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы

нигезләмәгә тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин